# Чаллы тагын күрештерде

Кайнар июльнең Питрау атнасына кердекме, керәшеннәр яшәгән төбәкләрдә җырлы-биюле җыеннар башлана. Ел саен шушы вакытта Чаллының Җиңү паркында Питрау бәйрәме уздыру да күркәм традициягә әверелде. Бу бәйрәмне керәшеннәр генә түгел, инде башка милләт вәкилләре дә түземсезләнеп көтеп ала башлады. Быел да 13 июльдә кичкырын матур-матур киенгән халык Җиңү паркына агылды.

Быел яңача корылган, бизәлгән сәхнә тамашачыны күңелле керәшен көйләрен яңгыратып каршы алды. Шул тирәдә эшмәкәрләр дә үзләренең сый-нигъмәт тулы өстәлләрен корып, сату оештырып җибәрде. Питрау сәхнәсенең хуҗалары — "Карендәшләр" керәшен халык фольклор ансамбле, "Ләке "подгорные" такмакларын сузып җибәреп, һәммәсен әйлән-бәйлән әйләнергә чакырды. Тамашачы, әйтерсең, шуны гына көткән, катлы-катлы түгәрәк ясап, җырлый-җырлый әйләнергә керешә.

Бәйрәмнең мәртәбәле кунаклары Чаллы муниципаль башкарма комитеты рәисе урынбасары Г.Каширина, шәһәр хакимиятенең культура һәм спорт бүлеге начальнигы Р.Мәҗитов, Чаллының Автозовод районы башлыгы А.Гыйниятуллина, Чаллы милли җәмгыять рәисләре, Удмуртия керәшен җәмгыяте рәисе В.Рязанов, Санкт-Петербургтан тарих фәннәре докторы В.Успенский һ.б.лар халыкны котларга сәхнәгә менде. Быел, гомумән, күрше-күлән районнардан килгән кунакларның күп булуы аеруча куанычлы күренеш булды. Түбән Кама, Менделеев, Алабуга керәшен җәмгыятьләре вәкилләренең килүе, Түбән Камадан Р.Петрова җитәкчелегендәге "Жиз кыңгырау", Алабугадан В.Мироваев җитәкчелегендәге "Ак каз" керәшен фольклор ансамбльләренең чыгышы Питрау бәйрәменә тагын да ямь өстәде. Шулай ук Кукмара егете, танылып килүче яшь җырчы Вадим Захаров, җырчы-композитор Ринат Гобәйдуллин, җырчы Дания Сибгатуллинаның чыгышларын тамашачы яратып алкышлады. Әлбәттә, Питрау бәйрәме шаян уеннардан башка узмый. Бәйрәмне алып баручы "Карендәшләр" ансамбле җитәкчесе Р.Ипеева кызык-кызык уеннар оештырып, халыкны рәхәтләнеп көлдерде, күңелен ачты. Башта тамашачы үзен куас эчүдә сынап караса, соңрак Питрау такыясы үрде, Питрау букеты җыйды. Питрау себеркесе бәйләргә исә иң оста, сыналган кешеләр чыкты. Җиңүчеләр тамашачы алкышлары нәтиҗәсендә билгеләнде. Иң яхшы себерке аукционда сатып та җибәрелде. Аннан соң халык арасыннан иң гүзәл кызларны сайлап алып, Питрау чибәре ачыкланды.

Быелгы Питрау бүләкләрнең күплеге, муллыгы белән аерылып торды. Сәхнәгә менгән һәркем бүләксез китмәде. Бәйрәмнең матди ягын тулысы белән шәһәрнең культура бүлеге, шулай ук А.Высоцкий, Н.Логинов, С.Хәбибуллин, А.Аппаков, Н.Агачев, В.Абрамов кебек асыл егетләр үз җилкәләренә күтәрде. Бу уңайдан Чаллы керәшен җәмгыяте рәисе Н.Ипеев һәммәсенә рәхмәтен җиткерде, ел буена җәмгыятьнең һәм керәшен ансамбленең эшчәнлегендә актив катнашкан кешеләргә истәлекле бүләкләр тапшырды.

Караңгы төшеп, күз бәйләнсә дә, бәйрәм күңелле итеп, җырлы биюләр белән дәвам итте. Танышлары, туган-тумачалары белән күрешкән халык таралырга ашыкмады. "Карендәшләр" ансамбле, шулай ук "Йолдызлык", "Ватаным—2007" конкурслары лауреаты булган "Замана" керәшен яшьләр ансамбле заманчалаштырылган керәшен җырларын яңгыратып тамашачының күңелен ачты.

**А.КЛИМОВА.**





